**Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре хакында бәяләмә**

«24» июнь, 2026 ел

**Гавами тыңлаулар уздыру урыны һәм вакыты:**

Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгеләргә:

2026 елның 24 июнендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Татар Тау Иле авыл җирлеге, Татар Тау Иле авылы,Совет урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында.

**Җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү ысулы:**

Гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүмат «Вперед» («Алга») район газетасының 2026 елның 10 июнендәге 22 номерлы (10682) санында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (http://pestreci.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) басылып чыкты һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылды.

**Гавами тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә:** җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проектын тикшерү.

**Гавами тыңлаулар үткәрү нигезе:** Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлеге башлыгының «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында» 2026 елның 8 июнендәге 5 номерлы карары.

**Гавами тыңлауларны оештыручы:** Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлеге башкарма комитеты.

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проектын карауда катнашучылар саны: 6 кеше.

Гавами тыңлауларда катнашучы һәм гавами тыңлаулар үткәрелә торган территориядә даими яшәүче гражданнардан җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы проект буенча гамәлдәге законнар нигезендә Нигезләнгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кермәде.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлегенең җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә

файдалануга рөхсәт бирү турындагы проектны карау буенча гавами тыңлаулар 2026 елның 24 июнендәге беркетмәсе нигезендә әзерләнде.

**Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча нәтиҗәләр:**

1. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турындагы проектны раслау хакында карар кабул итәргә тәкъдим итәргә .
2. Гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советына җибәрергә.
3. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы проект буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы әлеге Бәяләмәне Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

Гавами тыңлаулар рәисе: ____________________ /И.Р. Габдрахманов

Гавами тыңлаулар секретаре: ____________________ /А.М.Загидуллина